**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«01» август 2024 ел № 870

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "2024 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль программаны раслау турында" 2023 елның 28 ноябрендәге 1540 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Финанслау күләмнәре артуга бәйле рәвештә, юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм алардан килгән зыяннарның авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль программаны раслау турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 1540 номерлы карары белән расланган «2024 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны финанслау күләмнәрен һәм чыганаклары»н яңа редакциядә бәян итәргә

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 39,4 млн. сум тәшкил итә<br>Финанслау чыганаклары:<br>- җирле бюджет 4,4 млн. сум,<br>- Татарстан Республикасы бюджеты 35,0 млн. сум. |

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» IV бүлегенең 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 2024 елда 39,4 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджет хисабына-4,4 млн. сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан-35,0 млн. сум.».

1.3. «Шәһәрләрдә транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары» Знче кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма комитетының
2024 елның 01 августындагы 870 номерлы
карарына кушымта

«2024 елга Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районында юл хәрәкәте
иминлеген арттыру» максатчан
программасына 3нче кушымта

## Шәһәрләрдә транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлдерелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары

(мең сум)

| № т/с | Чаралар | Үтәү вакыты | Барлыгы финанслау күләме | Шул исәптән | | | Башкару өчен җаваплы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән | Муниципаль берәмлек акчалары исәбеннән | Бюджеттан тыш чыганаклардагы акчалар исәбеннән | | |
| Капитал салулар | | | | | | | | |
| 1 | Торак пунктларның юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү | 2024 | 20000 | 20000 | | | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе | юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу куркынычын киметү |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Асфальт-бетон белән капланган (асфальт буенча асфальт) юл-урам челтәрен ремонтлау | 2024 | 15000 | 15000 | | | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерү баш идарәсе | юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу куркынычын киметү |
| 3 | Программа кысаларында БДД буенча чаралар. Билгеләр кую, ясалма юл тигезсезлеген урнаштыру, юл билгеләре салу, җәяүлеләр өчен металл киртәләр урнаштыру | 2024 | 4400 | | 4400 | | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | юл-транспорт һәлакәтләре, шул исәптән җәяүлеләр катнашында килеп чыгу куркынычы киму |
| | **БАРЛЫГЫ** | | **39400,0** | **35000,0** | **4400,0** | | | |